МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛАГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от "24" 07.2017 № 255

Казан ш.

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибен раслау турында

"Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктына нигезләнеп, б о е р ы к б и р ә м :

1. Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелүнең кушымтада бирелгән тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Л.Р. Сафин

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгының 2017 елның
24 июльдәге № 255 боерыгы
белән расланды

## Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибе

1. Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибе (алга таба - Тәртип) "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктына нигезләнеп эшләнде.

Әлеге Тәртип эш бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә (алга таба - Министрлык, граждан хезмәткәрләре) иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте (алга таба - коммерциячел булмаган оешма) белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү процедурасын регламентлый.

Тәртип Министрлыкта алар өчен эшкә алучының вәкиле булып Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министры (алга таба - министр) торган Татарстан Республикасы граждан хезмәткәрләренә кагыла.

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү турында гариза (алга таба - Гариза) граждан хезмәткәре тарафыннан шушы Тәртипкә 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча язмача рәвештә төзелә.

3. Граждан хезмәткәре Гаризаны коррупциячел һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба - Җаваплы зат) тапшыра.

4. Җаваплы зат Гаризаны кергән көнендә шушы Тәртипкә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча гаризаларны теркәү Журналында терки.

5. Җаваплы зат Гаризаны алдан карау эшен гамәлгә ашыра һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаны алдан карау барышында Җаваплы зат Гаризаны тапшырган граждан хезмәткәреннән коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуының планлаштырылган функцияләрен билгеләүче язмача аңлатмаларны һәм документларны сорарга хокуклы.

Бәяләмәдә граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдим булырга тиеш.

6. Гариза теркәлгән көннән соңгы биш эш көненнән дә соңга калмыйча Җаваплы зат Гаризаны, Бәяләмәне һәм башка материалларны (булган очракта) теркәп, коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен министрга (аның Вазыйфаларын башкаручы затка) карау өчен тапшыра.

Министр (аның Вазыйфаларын башкаручы зат) Г аризаны алган көннән соңгы ике эш көне эчендә карар кабул итә.

7. Җаваплы зат министр (аның Вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан карар кабул ителгән көннән соңгы ике эш көне эчендә граждан хезмәткәренә Гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа Гаризаның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге мөдире белән таныкланган, министрның (аның Вазыйфаларын башкаручы затның) резолюциясе куелган күчермәсен кул куйдыртып тапшыра. Министрның (аның Вазыйфаларын башкаручы затның) резолюциясе куелган Гаризаның төп нөсхәсе граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибенә 1-нче кушымта

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрына

**(Ф.И.А., били торган вазыйфа һәм структур**

______________________________________________

**бүлекчә, яшәгән урын адресы**

______________________________

___________

**телефон номеры)**

# Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү турында ГАРИЗА

Миңа (кирәклесенең астына сызарга) ______________________________________________
(иҗтимагый оешманың,

______________________________________________________________________________
торак, торак-төзелеш, гараж кооперативының, яшелчәчелек, бакчачылык, дача кулланучылар кооперативының, күчемсез мөлкәт милекчеләре
______________________________________________________________________________
ширкәтенең аталышы)
______________________________________________________ сыйфатында түләүсез нигездә
________________________________________________________________________________белән
(бер кеше кулындагы башкарма органның яисә идарә коллегиаль органының аталышы)
идарә итүдә катнашырга, аның идарә коллегиаль органы составына керергә рөхсәт бирүне сорыйм.

**(дата)** **(имза)** **(фамилия, инициаллар)**

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибенә 2-нче кушымта

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү турында гаризаларны теркәү ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Дата | Үтенеч язуын бирүченең Ф.И.А., вазыйфасы | Гариза бирүченең имзасы | Теркәүченең Ф.И.А. | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |